РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 9 феврале** **Чистай шәһәре** **№ 13/4**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында»2021 елның 20 октябрендәге 10/7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 20 октябрендәге 10/7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәнең «Вәкаләтле орган карарларына, вәкаләтле органның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү» 5 бүлегендәге нигезләмәләре 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

1.2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәнең 3 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2. Әлеге карар, әлеге пункт үз көченә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Әлеге карарның 1.2 пункты 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советының
2022 елның 9 февралендәге
13/4 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы составына
керүче авыл җирлекләре территорияләрендә
муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, муниципаль җир контроленең индикатив күрсәткечләре исемлеге**

| **Төп күрсәткечләр** | **Максатчан күрсәткечләр** |
|---|---|
| Җир законнарын ачыкланган бозулар арасыннан юкка чыгарылган хокук бозулар проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елга планлы контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру планын үтәү проценты | 100% |
| Контроль (күзәтчелек) чаралар үткәргәндә муниципаль контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи затының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) нигезләнгән шикаятьләр проценты | 0% |
| Контроль (күзәтчелек) чараларының юкка чыгарылган нәтиҗәләре проценты | 0% |
| Тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән контроль (күзәтчелек) чаралары проценты | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында суд карарлары проценты | 95% |
| Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә юкка чыгарылган карарларның муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми санынннан проценты | 0% |

**Муниципаль җир контроленең индикатив күрсәткечләре исемлеге**

1) хисап чорында үткәрелгән планлы тикшерү чаралары саны;
2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;
3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә контроль объектының хисап чорында мондый параметрлардан читләшүен ачыклау нигезендә үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;
4) хисап чорында үткәрелгән контроль чараларның гомуми саны;
5) хисап чорында үткәрелгән контроль чараларның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү буенча контроль чаралар саны;
6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралар саны;
7) хисап чорында үткәрелгән профилактик чаралар саны;
8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;
9) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирелгән контроль чаралар саны;

10) хисап чорында карарлар кабул итү өчен вәкаләтле органнарга тапшырылган контроль чаралар саны;
11) хисап чорында тикшерү чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
12) прокуратура органнарына хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль чаралар үткәрүне килештерү турында гаризалар саны;
13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;
14) риск категорияләренә кертелгән контроль объектларының һәр категориясе буенча хисап чоры ахырына исәпкә алынган объектларының саны;
15) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның саны;
16) хисап чорында контроль чаралар үткәрелгән контрольдә тотылучы затларның саны;
17) хисап чорында комитетның вәкаләтле вазыйфаи затларының, комитет инспекторларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъвалау турында контрольлек итүче затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;
18) комитетның вәкаләтле вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында контрольлек итүче затлар тарафыннан суд тәртибендә җибәрелгән, хисап чорында игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;
19) хисап чорында муниципаль җир контролен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) гамәлдән чыгарылган контроль чаралар саны.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов